ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасында стратегик планлаштыру турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 20 февралендә
кабул ителде

1 бүлек. **Гомуми нигезләмәләр**

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон "Россия Федерациясендә стратегик планлаштыру турында" 2014 елның 28 июнендәге 172-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон) нигезендә Татарстан Республикасында стратегик планлаштыруның (алга таба – стратегик планлаштыру) хокукый нигезләрен, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының стратегик планлаштыру өлкәсендә вәкаләтләрен билгели һәм Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш максатын билгеләү, аны фаразлау, планлаштыру һәм программалаштыру барышында стратегик планлаштыруда катнашучылар арасында барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала.

2 статья. **Стратегик планлаштыруны хокукый җайга салу**

1. Стратегик планлаштыруны хокукый җайга салу Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә нигезләнә һәм федераль конституциячел законнар, Федераль закон, башка федераль законнар, шулай ук Россия Федерациясенең алар нигезендә кабул ителгән башка норматив хокукый актлары, әлеге Закон, Татарстан Республикасының башка законнары һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары, муниципаль норматив хокукый актлар нигезендә гамәлгә ашырыла.
2. Әлеге Законда кулланыла торган төшенчәләр һәм терминнар Федераль законда билгеләнгән мәгънәләрендә кулланыла.

## 2 бүлек. Стратегик планлаштыру өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының вәкаләтләре

### 3 статья. Стратегик планлаштыру өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының вәкаләтләре

Стратегик планлаштыру өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) Россия Федерациясе социаль-икътисадый үсеше өстенлекләре һәм максатлары белән килештерелгән Татарстан Республикасы социаль-икътисадый сәясәтенең өстенлекләрен, Татарстан Республикасы социаль-икътисадый үсешенең озак сроклы максатларын һәм бурычларын билгеләү;

2) Федераль закон, башка федераль законнар, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, әлеге Закон һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезләмәләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасында эшләнә торган стратегик планлаштыру документларының эчтәлегенә, аларны әзерләү тәртибенә, карауга һәм раслауга (хуплауга) таләпләр билгеләү;

3) Татарстан Республикасы вәкаләтләренә караган мәсьәләләр буенча стратегик планлаштыру документларын әзерләү һәм раслау (хуплау);

4) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан расланган (хупланган) стратегик планлаштыру документларын гамәлгә ашыруны мониторинглау һәм тикшереп тору;

5) Татарстан Республикасы дәрәҗәсендә эшләнә торган стратегик планлаштыру документларының килешенгән һәм нисбәтле булуын тәэмин итү;

6) Татарстан Республикасында стратегик планлаштыруны әлеге Законның 2 статьясында күрсәтелгән норматив хокукый актлар нигезендә гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү;

7) Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының уртак карамагындагы Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашырыла торган мәсьәләләр буенча федераль дәрәҗәдә эшләнә торган стратегик планлаштыру документларын формалаштыруда катнашу;

8) стратегик планлаштыру өлкәсендә Федераль закон, башка федераль законнар, Россия Федерациясе Президентының, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актлары, әлеге Закон, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләренә кертелгән башка вәкаләтләр.

4 статья. **Стратегик планлаштыру өлкәсендә Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарының вәкаләтләре**

Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары стратегик планлаштыру өлкәсендәге вәкаләтләрне Федераль закон нигезендә гамәлгә ашыралар.

3 бүлек. **Стратегик планлаштыру системасы**

5 статья. **Стратегик планлаштыруда катнашучылар**

Стратегик планлаштыруда катнашучылар:

1) Татарстан Республикасы Президенты;

2) Татарстан Республикасы Дәүләт Советы;

3) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты;

4) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары;

5) Татарстан Республикасы Хисап палатасы;

6) әлеге Законның 2 статьясында күрсәтелгән норматив хокукый актларда каралган очракларда башка органнар һәм оешмалар.

6 статья. **Стратегик планлаштыруда катнашучыларның вәкаләтләре**

1. Татарстан Республикасы Президенты:

1) Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш юнәлешләрен, максатларын, өстенлекләрен билгели һәм төгәлләштерә;

2) Татарстан Республикасы вәкаләтләре кысаларында стратегик максатларга ирешү юнәлешләрен һәм хәл ителергә тиешле мөһим мәсьәләләрне билгели;

3) Татарстан Республикасы Дәүләт Советына озак сроклы чорга Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясен тәкъдим итә;

4) стратегик планлаштыру өлкәсендә башка карарлар кабул итә.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы:

1) стратегик планлаштыру өлкәсендә законнар ярдәмендә җайга салуны гамәлгә ашыра;

2) озак сроклы чорга Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясен раслый;

3) Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты:

1) стратегик планлаштыру өлкәсендә бердәм дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруны тәэмин итүдә катнаша, күрсәтелгән өлкәдә норматив хокукый актлар проектларын әзерләүне оештыра һәм Татарстан Республикасы дәрәҗәсендә стратегик планлаштыруны методик тәэмин итүне гамәлгә ашыра;

2) стратегик планлаштыруның Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карамагындагы документларын әзерләү һәм корректировкалау тәртибен билгели һәм мондый документларны раслый (хуплый);

3) Татарстан Республикасы дәрәҗәсендә стратегик планлаштыруны методик яктан тәэмин итү тәртибен билгели;

4) Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документларын һәм алардагы күрсәткечләрне әзерләүнең эзлеклелеген һәм үзара бәйләнешен билгели, шулай ук стратегик планлаштыру документларын әзерләү өчен, Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш өстенлекләреннән чыгып, максатчан күрсәткечләр системасын формалаштыру тәртибен билгели;

5) Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары эшчәнлегенең максатларын, бурычларын һәм күрсәткечләрен билгели;

6) Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документларының килешенгән һәм нисбәтле булуын тәэмин итә;

7) Татарстан Республикасының түбәндәге стратегик планлаштыру документларын раслый:

а) уртача һәм озак сроклы чорга Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш фаразын;

б) озак сроклы чорга бюджет фаразын;

8) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карамагындагы мәсьәләләр буенча стратегик планлаштыру документларын мониторинглауны һәм аларны тикшереп торуны гамәлгә ашыра;

9) Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документларын гамәлгә ашыру турында хисаплар (докладлар) әзерләү тәртибен билгели;

10) Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документларына норматив һәм методик таләпләрне тикшереп торуны гамәлгә ашыра, моңа аларны әзерләү һәм корректировкалау эзлеклелегенә һәм тәртибенә карата таләпләр дә керә;

11) стратегик планлаштыру өлкәсендә федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

4. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары:

1) Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документларын әзерлиләр, Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документларын әзерләүне һәм корректировкалауны Федераль закон, әлеге Закон һәм әлеге Законның 2 статьясында күрсәтелгән норматив хокукый актлар нигезендә җайга салалар;

2) Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документларын гамәлгә ашыруны мониторинглауны һәм тикшереп торуны башкаралар;

3) стратегик планлаштыру өлкәсендә Федераль закон, әлеге Закон һәм әлеге Законның 2 статьясында күрсәтелгән норматив хокукый актлар нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыралар.

5. Татарстан Республикасы Хисап палатасы:

1) “Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында” 2004 елның 7 июнендәге 37-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә стратегик планлаштыру өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыра;

2) Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә стратегик планлаштыру өлкәсендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

**7 статья. Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документлары**

1. Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документларына түбәндәгеләр керә:

1) максатны билгеләү кысаларында әзерләнә торган стратегик планлаштыру документы – Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясе;

2) фаразлау кысаларында әзерләнә торган стратегик планлаштыру документлары, аларга түбәндәгеләр керә:

а) озак сроклы чорга Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш фаразы;

б) озак сроклы чорга Татарстан Республикасы бюджеты фаразы;

в) уртача сроклы чорга Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш фаразы;

3) планлаштыру һәм программалаштыру кысаларында эшләнә торган стратегик планлаштыру документлары, аларга түбәндәгеләр керә:

а) Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясен гамәлгә ашыру чаралары планы;

б) Татарстан Республикасы дәүләт программалары;

в) Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасы.

2. Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документларын әзерләү эзлеклелеге, тәртибе, аларның эчтәлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

**8 статья. Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документларын дәүләт теркәвенә алу**

Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документлары Федераль законның 12 статьясы нигезендә стратегик планлаштыру документларының федераль дәүләт реестрында мәҗбүри дәүләт теркәве узарга тиеш.

**9 статья. Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документлары проектлары буенча иҗтимагый фикер алышу**

1. Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документлары проектлары, Россия Федерациясе законнары, шул исәптән дәүләт, коммерция, хезмәт урыны сере һәм закон белән саклана торган башка сер турындагы Россия Федерациясе законнары таләпләрен исәпкә алып, иҗтимагый фикер алышуга чыгарыла.

2. Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документы проекты буенча иҗтимагый фикер алышуның рәвеше, тәртибе һәм сроклары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

3. Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документы проекты буенча иҗтимагый фикер алышу барышында алынган искәрмәләр һәм тәкъдимнәр Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документын әзерләү өчен җаваплы Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы тарафыннан каралырга тиеш.

4. Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документларының төп нигезләмәләре турындагы мәгълүматның ачыклыгын һәм аннан файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итү максатларында аларның проектлары Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документын әзерләү өчен җаваплы Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органының рәсми сайтында, шулай ук стратегик планлаштыруның “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге һәркем файдалана алырлык мәгълүмат ресурсында урнаштырылырга тиеш.

## 4 бүлек. **Татарстан Республикасының максатны билгеләү кысаларында әзерләнә торган стратегик планлаштыру документлары**

### 10 статья. **Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясе**

1. Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясе Татарстан Республикасы социаль-икътисадый үсешенең Россия Федерациясе социаль-икътисадый үсеше өстенлекләре һәм максатлары белән килештерелгән өстенлекләрен, максатларын һәм бурычларын билгеләү максатларында эшләнә.

2. Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясе Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш фаразы әзерләнә торган чордан артмаган вакытка алты ел саен эшләнә.

3. Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясенә түбәндәгеләр керә:

1) Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенең ирешелгән максатларын бәяләү;

2) Татарстан Республикасы социаль-икътисадый сәясәтенең өстенлекләре, максатлары, бурычлары һәм юнәлешләре;

3) Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеше максатларына ирешү күрсәткечләре, Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясен гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары;

4) Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясен гамәлгә ашыруның көтелә торган нәтиҗәләре;

5) Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясен гамәлгә ашыру өчен кирәкле финанс ресурсларын бәяләү;

6) Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясен гамәлгә ашыру максатларында раслана торган Татарстан Республикасы дәүләт программалары турында мәгълүмат;

7) Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнә торган башка нигезләмәләр.

4. Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясен әзерләү һәм корректировкалау тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

## 5 бүлек. **Татарстан Республикасының фаразлау кысаларында эшләнә торган стратегик планлаштыру документлары**

### 11 статья. **Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш фаразлары системасы**

1. Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешен фаразлау, Татарстан Республикасы социаль-икътисадый үсешенең ирешелгән нәтиҗәләрен, шулай ук барлыкка килгән икътисадый вәзгыятьне Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт сәясәтенең икътисад өлкәсендәге һәм социаль өлкәдәге стратегик максатлары һәм бурычлары нигезендә үзгәртү перспективаларын исәпкә алып, озак һәм уртача сроклы перспективага гамәлгә ашырыла.

2. Татарстан Республикасының озак сроклы чорга социаль-икътисадый үсеш фаразы, Россия Федерациясенең фәнни-технологик үсеш фаразын һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары тапшыра торган белешмәләрне исәпкә алып, Россия Федерациясенең озак сроклы чорга социаль-икътисадый үсеш фаразы нигезендә һәр алты ел саен унике һәм аннан күбрәк елларга әзерләнә.

3. Татарстан Республикасының уртача сроклы чорга социаль-икътисадый үсеш фаразы, Татарстан Республикасының бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләрен исәпкә алып, уртача сроклы чорга Россия Федерациясенең социаль-икътисадый үсеш фаразы, Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясе нигезендә ел саен әзерләнә.

4. Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш фаразлары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана (хуплана).

5. Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш фаразларын әзерләү һәм корректировкалау тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

### 12 статья. **Озак сроклы чорга Татарстан Республикасының бюджет фаразы**

Озак сроклы чорга Татарстан Республикасының бюджет фаразы Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә әзерләнә.

## 6 бүлек. Татарстан Республикасының планлаштыру һәм программалаштыру кысаларында әзерләнә торган стратегик планлаштыру документлары

### 13 статья. Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясен гамәлгә ашыру чаралары планы

1. Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясен гамәлгә ашыру чаралары планы, Россия Федерациясе Хөкүмәте эшчәнлегенең төп юнәлешләрен исәпкә алып, стратегияне башкару чорына Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясе нигезләмәләренә таянып әзерләнә.

2. Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясен гамәлгә ашыру чаралары планы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

3. Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясен гамәлгә ашыру чаралары планын корректировкалау Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән гамәлгә ашырыла.

4. Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясен гамәлгә ашыру чаралары планына түбәндәгеләр керә:

1) Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясен гамәлгә ашыруның, бюджет планлаштыруның билгеләнгән дәвамлылыгын исәпкә алып, бүленгән этаплары: өч ел (Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясен гамәлгә ашыруның беренче этабы һәм бюджет планлаштыруның агымдагы чоры өчен) һәм өч – алты ел (алдагы этаплар һәм чорлар өчен);

2) Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясен гамәлгә ашыруның һәр этабы өчен өстенлеккә ия Татарстан Республикасы социаль-икътисадый үсешенең максатлары һәм бурычлары;

3) Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясен гамәлгә ашыру күрсәткечләре һәм аларның стратегияне гамәлгә ашыруның һәр этабына билгеләнгән күрсәткечләре;

4) Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясен гамәлгә ашыруның һәр этабында Татарстан Республикасы социаль-икътисадый үсешенең стратегиядә күрсәтелгән озак сроклы максатларына ирешүне тәэмин итүче чаралар комплексы һәм Татарстан Республикасы дәүләт программалары исемлеге;

5) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән башка нигезләмәләр.

### 14 статья. Татарстан Республикасы дәүләт программалары

1. Татарстан Республикасы дәүләт программалары, Россия Федерациясенең стратегик планлаштыруның тармак документларын һәм Идел буе федераль

округының социаль-икътисадый үсеш стратегиясен исәпкә алып, Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясендә билгеләнгән социаль-икътисадый үсеш өстенлекләре нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән чорга әзерләнә.

2. Татарстан Республикасы дәүләт программалары исемлеге, аларны әзерләү, гамәлгә ашыру һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

3. Федераль дәрәҗәдә Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының уртак карамагындагы эшләргә кагылышлы максатларга ирешүгә юнәлдерелгән Россия Федерациясе дәүләт программасы расланган һәм гамәлгә ашырылган очракта, шундый ук Татарстан Республикасы дәүләт программасы әзерләнергә мөмкин.

4. Татарстан Республикасы дәүләт программалары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә раслана.

15 статья. **Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасы**

Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасы Татарстан Республикасының тотрыклы социаль-икътисадый үсешен тәэмин итү максатларында әзерләнә һәм, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында, Россия Федерациясенең территориаль планлаштыру схемаларында билгеләнгән таләпләрне исәпкә алып, Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясе, Идел буе федераль округының социаль-икътисадый үсеш стратегиясе нигезләмәләренә һәм Россия Федерациясенең стратегик планлаштыруның тармак документлары нигезләмәләренә таяна.

7 бүлек. **Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документларын гамәлгә ашыруны мониторинглау һәм тикшереп тору**

16 статья. **Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документларын гамәлгә ашыруны мониторинглау максаты һәм бурычлары**

1. Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документларын гамәлгә ашыруны мониторинглау максаты Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документларындагы төп социаль-икътисадый һәм финанс күрсәткечләрен комплекслы бәяләү нигезендә гамәлгә ашырыла торган стратегик планлаштыру системасының эшләү нәтиҗәлелеген арттырудан, шулай ук стратегик планлаштыруда катнашучыларның Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының һәм муниципаль берәмлекләрнең социаль-икътисадый үсешенең планлаштырылган күрсәткечләренә билгеләнгән срокларда ирешү буенча эшләү нәтиҗәлелеген арттырудан гыйбарәт.

2. Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документларын гамәлгә ашыруны мониторинглауның төп бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеше турында мәгълүматны җыю, системага салу һәм гомумиләштерү;

2) Татарстан Республикасы социаль-икътисадый үсешенең планлаштырылган максатларына ирешү дәрәҗәсен бәяләү;

3) икътисад секторларын һәм дәүләт, муниципаль идарә өлкәләрен планлаштыру һәм программалаштыру кысаларында әзерләнә торган Татарстан Республикасы стратегик планлаштыру документларының нәтиҗәлелеген һәм эффектив булуын бәяләү;

4) Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш максатларына ирешүнең план һәм факттагы дәрәҗәләренә эчке һәм тышкы институциональ факторларның, шартларның йогынтысын бәяләү;

5) Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документларын гамәлгә ашыруның планлаштырылган һәм факттагы срокларының, нәтиҗәләренең һәм шушы документларны башкару өчен кирәкле ресурсларның туры килүен бәяләү;

6) Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш дәрәҗәсен бәяләү, анализлау, ихтимал куркынычларны һәм хәтәрләрне ачыклау һәм аларны булдырмау өчен вакытында чаралар күрү;

7) стратегик планлаштыру системасының эшләү нәтиҗәлелеген арттыру буенча тәкъдимнәр әзерләү.

3. Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документларын гамәлгә ашыруны мониторинглау нәтиҗәләрен чагылдыручы Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш өлкәсендәге документларына түбәндәгеләр керә:

1) “Россия Федерациясе субъектлары закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында” 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясындагы 7 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Президентының еллык хисабы;

2) Татарстан Республикасы дәүләт программаларын гамәлгә ашыру барышы турында һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү хакында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының еллык җыелма доклады.

4. Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документларын гамәлгә ашыруны мониторинглауны башкару һәм Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документларын гамәлгә ашыруны мониторинглау нәтиҗәләрен чагылдыручы документларны әзерләү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

5. Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документларын гамәлгә ашыруны мониторинглау нәтиҗәләрен чагылдыручы документлар, дәүләт, коммерция, хезмәт урыны сере һәм законнар белән саклана торган башка сер турындагы белешмәләрдән тыш, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең стратегик планлаштыру документларын әзерләү өчен җаваплы органнарының рәсми сайтларында һәм стратегик планлаштыруның “Интернет” челтәрендәге һәркем файдалана алырлык мәгълүмат ресурсында урнаштырылырга тиеш.

17 статья. **Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документларын гамәлгә ашыруны тикшереп тору бурычлары**

1. Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документларын гамәлгә ашыруны тикшереп тору бурычлары түбәндәгеләр:

1) Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеше турында мәгълүматны җыю, системага салу һәм гомумиләштерү;

2) максатны билгеләү, фаразлау, планлаштыру һәм программалаштыру кысаларында эшләнә торган Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документларының сыйфатын бәяләү;

3) стратегик планлаштыру процессында кабул ителгән карарларның нәтиҗәлелеген һәм эффектив булуын бәяләү;

4) Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш максатларына ирешүне бәяләү;

5) Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш максатларына ирешүнең планлаштырылган һәм факттагы дәрәҗәсенә эчке һәм тышкы факторларның тәэсирен бәяләү;

6) стратегик планлаштыру системасының эшләү нәтиҗәлелеген арттыру буенча тәкъдимнәр әзерләү.

2. Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документын гамәлгә ашыруны тикшереп торучы орган тикшерү нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органына яисә Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документында планлаштырылган чараларны үткәрү яисә куелган күрсәткечләргә ирешү өчен җаваплы оешма җитәкчесенә мәгълүмат җибәрә.

3. Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документларын гамәлгә ашыруны тикшереп тору Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

8 бүлек. **Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документларын гамәлгә ашыру**

18 статья. **Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документларын гамәлгә ашыру**

1. Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясен гамәлгә ашыру Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясен гамәлгә ашыру чаралары планын әзерләү юлы белән башкарыла. Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясе нигезләмәләре, ресурслар белән тәэмин итү кирәклеген исәпкә алып, Татарстан Республикасы дәүләт программаларында төгәлләштерелә, моңа Россия Федерациясенең озак сроклы чорга бюджет фаразында һәм Татарстан

Республикасының озак сроклы чорга бюджет фаразында билгеләнгән ресурслар белән тәэмин итү дә керә.

2. Татарстан Республикасы социаль-икътисадый үсеш стратегиясенең төп нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары комплексы һәм Татарстан Республикасы дәүләт программалары исемлеге Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясен гамәлгә ашыру чаралары планына кертелә.

3. Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясен гамәлгә ашыру өчен кирәкле Татарстан Республикасы дәүләт программалары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә һәм Татарстан Республикасы дәүләт программалары исемлегенә кертелә.

4. Татарстан Республикасының һәр дәүләт программасын гамәлгә ашыру нәтиҗәлелеге ел саен бәяләнә. Күрсәтелгән бәяләүне үткәрү тәртибе һәм аның критерийлары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясен гамәлгә ашыру чаралары планын үтәү барышы турында еллык хисап әзерли.

9 бүлек. **Йомгаклау нигезләмәләре**

19 статья. **Йомгаклау нигезләмәләре**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документларын әзерләү һәм корректировкалау, Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документларын гамәлгә ашыруны мониторинглау һәм тикшереп тору тәртибен билгели торган норматив хокукый актлар кабул итәргә, Татарстан Республикасының стратегик планлаштыру документларын Федераль законның 47 статьясында билгеләнгән сроклар нигезендә әзерләүне тәэмин итәргә тиеш.

3. Әлеге Закон үз көченә кергән көнгә кадәр кабул ителгән стратегик планлаштыру документлары билгеләнгән сроклары тәмамланганчы гамәлдә дип санала.

4. Татарстан Республикасы дәүләт программалары гамәлдә булу чорлары тәмамланганчы гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2015 елның 16 марты
№ 12-ТРЗ